**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **12.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге составына керүче Бүләк авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлдерергә:

- Бүләк авылында юлларны кардан чистарту;
- Бүләк авылында кече авыл бәйрәмен оештыру һәм үткәрү;
- янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, янгын сүндерү автомобиле йөртүченең хезмәт хакы;
- Бүләк авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге Башлыгы М.Р.Шәрипов